ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 176

«10» 03 2021

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 2019 елның 17 сентябрендәге 631 номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм административ регламентны гамәлдәге Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан, ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 17 сентябрендәге 631 номерлы карары белән расланган җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.Регламентның 2.5 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;».

1.2. Регламентның 2.5 пунктындагы 8 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://www.pravo.tatarstan.ru басылып чыгарга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р. Закировка йөкләргә.

Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин